**Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы**
**дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 298-36 «29» август 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2022 елның 12 октябрендәге 171-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2022 елның 12 октябрендәге 171-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (14.12.2022 №188-20, 18.04.2023 №208-24, 25.10.2023 №241-27, 14.12.2023 №255-29, 28.03.2024 №270-32 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 8 пунктында:

- алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) физик һәм юридик затларның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен акчалата түләүләре өчен кирәкле сумманы, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булып торучы башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына кертә, моңа Россия Федерациясе законнарында каралган очраклар керми;»;

- түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчаны өстәргә:

«8) бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, өстәмә түләүләр һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс Министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;»;

- 8 пунктчаны 9 пунктча дип санарга;

1.2 14 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль контрактлар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, хезмәтләр күрсәтү сатып-алу план-графигы нигезендә төзелә (Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелергә тиешле сатып алу очракларыннан тыш), һәм, РФ БК 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә.».

1.3. 48 статьяның икенче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт (муниципаль) программалар һәм бюджет турындагы закон (карар) проектына эшчәнлекнең программада каралмаган юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү бюджеты турындагы закон (карар) белән расланган очракта, дәүләт (муниципаль) программаларының (күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары) паспортлары (паспорт проектлары) тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин